**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**РУКОВОДИТЕЛЬ**
**Исполнительного комитета**
**Азнакаевского**
**муниципального района**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы**
**башкарма комитеты**
**ҖИТӘКЧЕСЕ**

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре,
423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

## ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

**«30» июль 2019 ел** **№ 236**

Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 17.03.2011 ел №47 «Азнакай муниципаль районының муниципаль учреждениеләре (өстәмә белем бирү учреждениеләре) типлары һәм аларның уставларын яңа редакциядә раслау турында» карары белән расланган Азнакай шәһәре Балалар иҗаты үзәге Уставына үзгәреш кертү турында (20.10.2015 №281, 10.09.2018 №244 карарлар редакциясендә)

ТР Азнакай муниципаль районының Азнакай шәһәре Балалар иҗаты үзәге Уставын Россия Федерациясенең 29.12.2012 №273 – ФЗ «Россия Федерациясендә мәгариф турында» гы Федераль законына туры китерү максатыннан карар бирәм:

1. Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 17.03.2011 ел №47 «Азнакай муниципаль районының муниципаль учреждениеләре (өстәмә белем бирү учреждениеләре) типлары һәм аларның уставларын яңа редакциядә раслау турында» карары белән расланган Азнакай шәһәре Балалар иҗаты үзәге Уставына (20.10.2015 №281, 10.09.2018 №244 карарлар редакциясендә) үзгәреш кертергә:

**1.1. түбәндәге эчтәлекле 7 бүлек белән тулыландырырга:**

«7 Локаль норматив актларны кабул итү тәртибе

7.1. Учреждение үз эшчәнлеген регламентлаштыручы локаль, локаль норматив актлар (мәгариф һәм тәрбия процессын оештыру, идарә органнары эшчәнлеген оештыру, административ һәм финанс-хуҗалык эшчәнлеген оештыру, методик эш һәм конкурслар уздыру) кабул итәргә хокуклы, мәсәлән: нигезләмәләр, боерыклар, кагыйдәләр, тәртипләр, инструкцияләр, актлар, карарлар, планнар, графиклар, расписание, шартнамәләр һ. б.

7.2. Учреждениенең локаль актлары, локаль-норматив актлары Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына әлеге Уставка һәм хезмәт шартнамәсенә каршы килә алмый.

Локаль норматив актлар учреждение директоры боерыгы (коллегиаль органнар фикерләрен исәпкә алып) белән гамәлгә кертелә
7.3 Учреждение кирәк булганда гамәлдәге локаль актларны үзгәртергә яки гамәлдән чыгарырга хокуклы.
7.4. . Расланганнан соң, локаль норматив акт учреждениенең рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.
7.5. Белем бирү турындагы законнар, хезмәт законнары белән чагыштырганда яки билгеләнгән тәртипне бозып кабул ителгән учреждение укучылары яки хезмәткәрләренең хәлен начарайта торган локаль норматив акт нормалары учреждение тарафыннан кулланылмый һәм юкка чыгарылырга тиеш.». 1.2. 7 һәм 10 бүлекләрне 8 һәм 11 бүлекләр дип санарга.

2. «Азнакай шәһәре балалар иҗаты үзәге» директоры (Хәсәнова Р. М.) гамәлдәге законнар нигезендә, Уставка үзгәрешләр кертергә, дәүләт теркәвенә алырга вәкаләтле.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында»: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет - телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары
Д.Р. Гыйләҗевка йөкләргә.

Җитәкче А.Х.Шәмсетдинов

«РАСЛАНГАН»
Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты карары
«____ »___________2019  №______

____________________А.Х.Шәмсетдинов

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «АЗНАКАЙ ШӘҺӘРЕ БАЛАЛАР ИҖАТЫ ҮЗӘГЕ» ӨСТӘМӘ БЕЛЕМ БИРҮ МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ ОЕШМАСЫ УСТАВЫНА ҮЗГӘРЕШЛӘР**

Азнакай шәһәре

Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 17.03.2011 ел №47 «Азнакай муниципаль районының муниципаль учреждениеләре (өстәмә белем бирү учреждениеләре) типлары һәм аларның уставларын яңа редакциядә раслау турында» карары белән расланган Азнакай шәһәре Балалар иҗаты үзәге Уставына (20.10.2015 №281, 10.09.2018 №244 карарлар редакциясендә) үзгәреш кертергә:

1.1. түбәндәге эчтәлекле 7 бүлек белән тулыландырырга:

«7 Локаль норматив актларны кабул итү тәртибе

7.1. Учреждение үз эшчәнлеген регламентлаштыручы локаль, локаль норматив актлар (мәгариф һәм тәрбия процессын оештыру, идарә органнары эшчәнлеген оештыру, административ һәм финанс-хуҗалык эшчәнлеген оештыру, методик эш һәм конкурслар уздыру) кабул итәргә хокуклы, мәсәлән: нигезләмәләр, боерыклар, кагыйдәләр, тәртипләр, инструкцияләр, актлар, карарлар, планнар, графиклар, расписание, шартнамәләр һ. б.

7.2. Учреждениенең локаль актлары, локаль-норматив актлары Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына әлеге Уставка һәм хезмәт шартнамәсенә каршы килә алмый.

Локаль норматив актлар учреждение директоры боерыгы (коллегиаль органнар фикерләрен исәпкә алып) белән гамәлгә кертелә

7.3 Учреждение кирәк булганда гамәлдәге локаль актларны үзгәртергә яки гамәлдән чыгарырга хокуклы.

7.4. . Расланганнан соң, локаль норматив акт учреждениенең рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

7.5. Белем бирү турындагы законнар, хезмәт законнары белән чагыштырганда яки билгеләнгән тәртипне бозып кабул ителгән учреждение укучылары яки хезмәткәрләренең хәлен начарайта торган локаль норматив акт нормалары учреждение тарафыннан кулланылмый һәм юкка чыгарылырга тиеш.».

1.2. 7 һәм 10 бүлекләрне 8 һәм 11 бүлекләр дип санарга.